Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе
Салагыш урта гомуми белем бирү мәктәбе

«Каралды»
МБ җитәкчесе
_____Гиззатуллина В.Р.
Протокол № 1____
«      » август  2022 ел

«Килешенде»
Укыту-тәрбия эшләре
буенча директор
урынбасары
____Фархушина Л.Г..
«        »  август 2022 ел

«Раслыйм»
Мәктәп директоры
_____Ахметзянова Л.М.
Приказ № 115- О от
«31» август 2022 ел

**Гыйззәтуллина Венера Рифкать кызының**
5 сыйныф өчен
« Туган якны өйрәнү » курсы буенча

**дәрестән тыш эшчәнлек ПРОГРАММАСЫ**

Педагогик киңәшмә
утырышында каралды.
Беркетмә №1, 31август, 2022

2021 - 2022 уку елы

**Аңлатма язуы**

Яңа стандартларның төп максаты – шәхес тәрбияләү, бәләкәйдән үк баланы шәхес итеп күрү, аның сәләтен күрә белү, аны үстерүгә ярдәм итү, иҗади баскычка күтәрү. Хәзер башлангыч сыйныф укытучысы укучыны укырга, язарга, санарга гына өйрәтеп калырга түгел, ә универсаль уку күнекмәләре формалаштырырга, проект эшчәнлегенең эксперты, җитәкчесе булырга да тиеш. Яңа стандартлар традицион программаларда кертелгән артык информациядән котылырга, репродуктив укыту алымыннан эзләнүле укыту алымына күчәргә, укучының үзбәясен күтәрергә ярдәм итәчәк. Бала үзе эзлекле рәвештә белем туплый белергә тиеш. Аны яңалыкка омтылучы, заман сулышын тоючы, белемен өзлексез камилләштерүче, укыту-тәрбия эшенә иҗади якын килүче укытучы гына тормышка ашыра ала. Р.Уотермен “Хәзерге эшлекле заманда үзгәрешләрдән дә даимирәк нәрсә юк “ дигән. Яңа стандартларга күчү барышында укучы шәхесен күпкырлы үстерүдә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә төрле инновацияле технологияләр кулланыла. Балаларны үз илләрен яратучы көчле рухлы шәхесләр итеп тәрбияләү өчен дәресләр белән беррәттән дәрестән тыш эшчәнлекнең дә роле зур. “Туган якны өйрәнү” эшчәнлегенең программасы менә шушы проблемаларны, таләпләрне хәл итү максатыннан төзелде. Бала көннең күп өлешен мәктәп диварлары арасында үткәрә. Укучының физик, психик сәламәтлеге турында кайгырту, аны саклау максатыннан “Туган якны өйрәнү” эшчәлеген мавыктыргыч итеп кызыклы очрашулар, файдалы әңгәмәләр, сәяхәт – экскурсияләр, җырлы – биюле уеннар, эзләнү эшләре аша һәм күп төрле эш алымнарыннан файдаланып үткәрергә була.

Халкыбызның тарихын белү, аңлау, телен – динен хөрмәт итү, милләт өчен борчылу, гореф – гадәтләрен, җыр – моңнарын күңел аша үткәрү бала зиһенен баета, күңел офыгын киңәйтә. Туган як турында өйрәнгәндә әби – бабаларыбызның мәгънәле тормышын күрсәткән шөгыльләрен, һөнәрләрен, гореф – гадәтләрен балалар күңеленә салып калдыру кирәк.

Рухи байлык – ул бик киң төшенчә. Аңа сәнгатьнең барлык төрләре – халкыбызның гасырлар буе яшәп килгән гореф – гадәтләре, әхлак кагыйдәләре, тормышның һәр өлкәсендә тупланган халык акылы, аның тормыш тәҗрибәсе керә.Ләкин үз халкыңның бу байлыгын бөтен нечкәлеге белән аңлау һәм үзләштерү, яшәгән нигезеңне, авылыңны өйрәнеп белүдән башка мөмкин түгел. Шуңа күрә туган төбәгеңнең тарихын өйрәнү игелекле эшләрнең берседер.Туган якны өйрәнү – балаларда милләтебез белән горурлану хисе тәрбияли. Татарның милли сыйфатлары белән танышу мөмкинлеге бирә. Милли сыйфатлар: мөстәкыйльлек, татарның башка халыклар белән аралаша белүе, мәгърифәтле, кунакчыл, чиста – пөхтә, батыр, бай тормышлы булуы, сәүдә эшенә хирыслыгы ул. Башлангыч мәктәп - балаларны һәрьяклап үстерүгә нигез сала һәм Ватанга мәхәббәт, туган авылга, кешеләргә хөрмәт тәрбияләргә бурычлы. Бу бурычны хәл итүдә ана теле, уку, әйләнә - тирә һ.б. фәннәр белән беррәттән “Туган якны өйрәнү”

эшчәнлегенең роле зур. Бу балаларның һәрьяклап, күпкырлы үсешенә ирешергә зур мөмкинлек тудыра. Эшчәнлектә балаларның мөстәкыйль фикер йөртүен, буш вакытларын дөрес үткәрүләрен, аларның кызыксынучанлыгын, эзләнүчән, игътибарлылыгын үстерүдә һәм аңа җитәкчелек итүдә мөмкинлек туа.
Тәкъдим ителә торган программа үзенең актуальлеге, яңалыгы, тормышчанлыгы белән аерылып тора. Ул туган як турында белемнәрне арттыру, эзләнүчәнлекне, интеллектлылыкны үстерү, иҗади сәләтне ачуны да үз эченә алган.

**Программа түбәндәге бүлекләрне үз эченә ала.**

1. Кеше һәм яшәүнең мәгънәсен аңлату.
   Туган җир, туган як, туган авыл тарихы. Ата – бабаларыбызның үткәне. Нәсел шәҗәрәсен төзү.
2. Әби – бабайлардан калган кадерле әйберләрнең эшләнү, барлыкка килү һәм аларның җиде буын җылысын саклавын өйрәтү.
3. Халык педагогикасына нигезләнеп, татар балалар фольклорын, халык авыз иҗатын өйрәнү. Милли бәйрәмнәргә, йолаларга, милләтнең традицияләренә мәхәббәт, ихтирам тәрбияләү.
   Дәрестән тыш эшчәнлекнең башлангыч этабы ана теле, уку дәресләре эчтәлеге белән тыгыз бәйләнгән. Укучыларга бу дәресләрдә әдәби тел нормалары белән беррәттән матурлыкны күрүгә, туган җиребезне яратуга, табигатьне саклау-га, фольклорны өйрәнүгә зур урын бирелә. Шушы нигездә дәрестән тыш эшчәнлектә укучыларга тарихның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында башлангыч мәгълүмат бирү, укучыларда әти - әниләренә, үзләренә, иптәшләренә, игътибар, аңлы караш һәм укуга һәвәслек тәрбияләү бурычы куела.

**Программаның максаты һәм бурычлары:**

1. Яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, балаларның мөстәкыйльлеген үстерү.
2. Балаларның иҗади активлыгын, иҗади сәләтен күрү, ачу, аларны үстерү юлларын табу.
3. Предметара бәйләнешләр булдырып, фикерләү сәләтләрен үстерү, алынган белем – мәгълүматларны камилләштерү, киңәйтү, бер системага салу.
4. Балаларны күзәтергә, эзләнергә, фикерләргә, шул фикерне ачык итеп әйтә белергә, проект эшендә куллана белергә өйрәтү.

5. Эстетик тәрбия бирү. Сөйләм культурасына, үз – үзенә таләпчәнлек, намуслылык, ныклы һәм тәвәккәл холык, зәвыклы балалар тәрбияләү.
6. Китап өстендә эшләргә өйрәтү. Танып – белү, образлы һәм логик фикерләү сәләтен үстерү, сөйләмнәрен баету.
7. Өйрәнелә торган материалны анализлау, тарихи момент һәм фактларны аңлата һәм исбатлый белү. Акыл эшчәнлеген үстерү.

**Программаның бүлекләре һәм юнәлешләре.**

*1. Туган җир, туган як, туган авыл тарихы. Ата – бабаларыбызның үткәне. Нәсел шәҗәрәсен төзү.*

- Эшчәнлек һәм аның исеменең асылына төшендерү юлларын эзләү; Балага яшәүнең мәгънәсен, кыйммәтен аңлату; “Мин” дигән төшенчәне аңлавына ирешү;
- Коллективлык хисләре, хезмәт сөючәнлек һәм укуга уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- Туган як табигате байлыклары үрнәкләрен туплау: фотосурәтләр җыю, тарихи документлар, күренекле кешеләрнең тормыш юллары тасвирланган язмалар, кулъязмалар туплау.

2. *Әби - бабайларның күңел байлыгын кушып эшләнгән эшләрен өйрәнү.*

- Әбиләребезнең күңел җылысы салынып чигелгән, кулдан тукылган, тегелгән сөлге, тастымал, алъяпкыч, намазлык, кашага, аяк чолгавы, мендәр тышы, тәрәзә челтәрләре җәүһәрләре белән танышу;
- Бабайларыбызның үткен зиһене, оста куллары аша үткән төрле – төрле туку, сугу, эрләү җайланмалары, агач һәм тимердән эшләнгән савыт – сабалар белщн танышу;
- Зәрканчылык һөнәре турында өйрәнү.

2. *Халык педагогикасына нигезләнеп, татар балалар фольклорын өйрәнү. Милли бәйрәмнәр, йолалар, милләтнең традицияләре турында белү.*

- Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән рухи хәзинәләребезне саклап калу;
- Онытыла башлаган гореф – гадәтләрне, йолаларыбызны барлап, иң матурларын сайлап алып , балаларга өйрәтү.

**Бу эшчәнлек барышында үтемлелек, дәвамчанлык, переспективалылык принциплары тормышка ашырылырга тиеш.**

**Прграмманы тормышка ашыру шартлары:**

- Каралган барлык теоретик материалны өйрәнү һәм барлык практик шөгыльне үтәү.
- Һәр балага индивидуаль якын килү, һәр балага шәхес итеп карау.
- Барлык дидактик материалдан һәм информацион - коммуникатив технология чараларыннан файдалану.

**Эшчәнлекнең формалары:**

- әңгәмәләр;
- рольле уеннар;
- хәрәкәтле уеннар;
- халкыбызның җырлы – биюле уеннары;
- китап укучылар конференциясе;
- анкеталар;
- тестлар;
- экскурсияләр;
- очрашулар.

**Эшчәнлекнең нәтиҗәсе:**

- Укучыларны дәрестән тыш эшчәнлеккә тартып, аларның активлыгын үстерү.
- Мәктәп, район, республика, күләмендә оештырыла торган интелектуаль уен, конкурсларда актив катнашырга тырышу.
- Балалар арасындагы дуслык, бердәмлек, коллективта үз – үзеңне тотуның югары мөмкинлекләрен булдыру.

**Программа атнага 1 сәгать исәбеннән төзелгән.**

Пояснительная записка .

Основная цель новых стандартов-воспитание личности, смотреть на ребенка с детства как личности, его способности видеть, способствовать его развитию, поднимать на творческий уровень. Теперь учитель начальных классов должен не только научить ученика читать, писать, считать, но и формировать универсальные учебные навыки, быть экспертом, руководителем проектной деятельности. Новые стандарты помогут избавиться от избыточной информации, включенной в традиционные программы, перейти от репродуктивного подхода к поисковому обучению, повысить самооценку ученика. Ребенок сам должен уметь последовательно набирать знания. Его может реализовать только учитель, стремящийся к новизне, ощущающий дыхание времени, непрерывно совершенствующий свои знания, творчески приближающийся к учебно-воспитательной работе.

## ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ ОСНОВНОГО СОДЕРЖАНИЯ УЧЕБНОГО ПРЕДМЕТА

5 класс (1 ч. в неделю, всего 35 ч.)

| **№ п/п** | **Кол - во часов** | **Содержание учебного материала** | **Модуль школьный урок** | **Требования к уровню общеобразовательной подготовки учащихся** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 5 ч. | История родного края | Привитие любви к родному краю.<br>Развитие активного интереса к её прошлому и настоящему.<br>Воспитание интереса к учению, | Ознакомление учащихся с историей сел Салагыш, Уразаево, Ямурза.<br>Заочное путешествие по достопримечательностям Салауши. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | процессу познания. Формирование бережного отношения к материальным и духовным ценностям. Формирование научного мировоззрения, убеждений. Формирование позитивной самооценки, навыков совместной деятельности со взрослыми и сверстниками, умений сотрудничать друг с другом, совместного планирования своих действий и реализации планов, поиска и систематизировать нужную информацию. Воспитание активной жизненной позиции, нравственно-этических принципов и привычек. | Экскурсия в музей. Знакомство с различными рукописями,фотографиями, воспоминаниями, материалами печати. |
| 2. | 2 ч. | Великая Отечественная война и мои односельчане. | Формирование умения прогнозировать события. Воспитание любви к познанию прошлого своего родного края. Воспитание ответственного поведения. | Пополнение знаний о судьбах солдат - односельчан, участников Великой Отечественной войны, о ветеранах тыла, о детях войны. (путешествие в музей) |
| 3. | 3 ч. | Природные богатства родного края | Формирование ценностного | Изучение природных богатств, животного мира |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | отношения к природе через общечеловеческие ценности жизни, осознавая себя частью природного мира.<br>Привитие бережного отношения к среде обитания человека и переживание чувства красоты, гармонии, совершенства. | родного края. Наш край –это изучение о растущих на лугах травах, о лебедях,которые прилетают на пруды, о животных. |
| 4. | 4 ч. | Знаменитые люди нашего села. | Воспитание уважительного отношения к носителям лучших человеческих качеств: трудолюбие, мастерство, чувство собственного достоинства, доброта, щедрость, физическая сила. | Исследование о знаменитых уроженцах села. (Путешествие в музей, встреча) |
| 5. | 2 ч. | Не уходите из детства! | Формирование представлений о нравственных нормах, освоение культуры поведения в семье, школе, в общественных местах. | Изучение школьной истории села, жизни тех учителей, кто преподавал в те годы, о судьбе выпускников школ. (встреча) |
| 6. | 2 ч. | Моя семья-моя радость | Воспитание чувства благодарности, взаимной ответственности. | Составление семейной родословной. |
| 7. | 7 ч. | История Агрызского района. | Формирование уважительного отношения к родному краю, к | Экскурсия в Агрызский район(заочная экскурсия) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | его природе и культуре, истории и современной жизни. | |
| 8. | 3 ч. | “Салагышым минем” | Воспитание нравственных и гражданских качеств. Формирование чувства гордости и любви к Родине, развитие активного интереса к её прошлому и настоящему. | Изучение песен о родном крае. |
| 9. | 6 ч.<br><br>1 ч. | Праздники<br><br>Итоговое занятие | Воспитание любви к народу, к его праздникам и традициям. | Поиск, обзор, изучение собранных материалов, проектная работа. |

| № | Тема | План буенча | Фактик | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Туган авыл тарихы.<br>Яшәгән төбәк белән танышу.<br>Укучыларны Салагыш, Уразай, Ямурза авыллары тарихы белән таныштыру. | 01.09 | | |
| 2 | Туган якның истәлекле урынары.<br>Салагышның истәлекле урыннарына читтән торып сәяхәт ясау. | 08.09 | | |
| 3 | “Авылым тарихы эзләре буйлап”<br>Музейга сәяхәт | 15.09 | | |
| 4 | Туган як турында материалларны өйрәнү<br>Төрле кулъязмалар,фотолар, истәлекләр, матбугат материаллары белән танышу. | 22.09 | | |
| 5 | “Гасыр кичкән буын”<br>Бөек Ватан сугышында катнашучы авылдаш - солдатлар язмышы,тыл ветераннары, сугыш чоры балалары турында белемнәрне тулыландыру.<br>(музейга сәяхәт) | 29.09 | | |
| 6 | Туган якның табигый байлыкларын, хайваннар дөньясын өйрәнү.<br>Безнең як урман –кыр –болыннарда үсә торган үләннәр, буага килә торган аккошлар,хайваннар турында өйрәнү.<br>(презентация) | 06.10 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **7** | Шушы яктан, шушы туфрактан без..<br>Авылдан чыккан күренекле шәхесләр турында өйрәнү.<br>(Музейга сәяхәт, очрашу) | 13.10 | | |
| 8 | Китмәгез сез балачактан!<br>Авылның мәктәп тарихын, кайсы елларда кемнәр укыткан,шул укытучылар тормышы, мәктәптән укып чыкан укчылар язмышы турында өйрәнү.<br>(очрашу) | 20.10 | | |
| 9 | Гаиләм - шатлыгым<br>Гаилә шәҗәрәсе төзү. | 27.10 | | |
| 10 | Әгерже районы тарихы.<br>Әгерже  районына сәяхәт(читтән экскурсия) | 10.11 | | |
| 11 | “Әгерже хәбәрләре” газетасы тарихы<br>Газетаның кайсы елларда нинди исем белән чыгуын өйрәнү.<br>(Читтән экскурсия) | 17.11 | | |
| 12 | Әгерженең алтын каләме, еракларга китә сәламе.<br>Районлаш язучылар һәм шагыйрьләр белән танышу. Балалар газета-журналларына язган укучыларның язмалары белән даими танышып бару.<br>(әңгәмә) | 24.11 | | |
| 13 | Әгерже язучылары. | 01.12 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Әгерҗе районыннан чыккан язучылар иҗаты белән өлешчә танышу.<br>Әңгәмә, презентация | | | |
| 14 | Ямурза,Уразай,Салагыш ягы күренекле кешеләре.<br>Авылларыбыздан чыккан артистлар, фән эшлеклеләре, хезмәтләре белән район тарихында зур хөрмәткә лаеклылар турында өйрәнү. | 08.12 | | |
| 15 | “Уйланабыз, эзләнәбез, авылым синең хакта”<br>Укучыларның белемнәрен арттыру максатыннан тестлар эшләү,хикәя язу,кроссворд чишү.<br>Гамәли эзләнү. | 15.12 | | |
| 16 | “Салагышым минем”<br>Туган як турындагы җырларны өйрәнү.<br>Әңгәмә,җырлы – биюле уеннар. | 22.12 | | |
| 17 | “Салагышым – туган ягым”<br>Иншалар һәм рәсемнәр конкурсы | 12.01 | | |
| 18 | Челтер – челтер ага елгалар.<br>Елгаларга сәяхәт ясау, килеп чыгу тарихын өйрәнү.<br>Читтән торып сәяхәт | 19.01 | | |
| 19 | Мәктәбем – горурлыгым,<br>Мәктәбем – йөз аклыгым.<br>Салагыш мәктәбенең үткәне һәм бүгенгесенә | 26.01 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | сәяхәт.<br><br>Әңгәмә, музейга экскурсия | | | |
| 20 | Без авылның киләчәге.<br><br>(Татарстан Республикасы, Казан шәһәре тарихын да өйрәнергә була)<br>Өйрәнелгәннәрдән чыгып, китапчык төзү.<br>Әңгәмә | 02.02 | | |
| 21 | Әби –бабайларның күңел байлыгын кушып эшләнгән эшләрен өйрәнү.<br>Халкыбызның күңел җәүһәрләре.<br><br>Авыл кешеләренең кулдан тукылган, чигелгән, тегелгән сөлге, тастымал. Күлмәк, калфак, бәйләнгән тәрәзә челтәрләре, самовар япкычлары һ.б. алар турында өйрәнү.<br>Презентация, музейга экскурсия | 09.02 | | |
| 22 | Зәркан сәнгате.<br>Борынгыдан килгән милли бизәнү әйберләре турында өйрәнү.<br>Эзләнү, презентация | 16.02 | | |
| 23 | Кулдан ясалган эш кораллары.<br>Бабайларыбыз нинди эш кораллары ясаганнар һәм аларны кайсы эшләрдә кулланганнар? | 02.03 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Әңгәмә, эзләнү | | | |
| 24 | Остаханә - осталар иле.<br>Беләзек, чулпы, калфак, чигү үрнәкләре буенча бизәнү әйберләрен эшләү.<br>Проект эше | 09.03 | | |
| 25 | Матурлык – туган өйдән башлана.<br>Хәзерге заман ысуллары белән ясалган бизәнү әйберләрен өйрәнү, ясау.<br>Күргәзмә | 16.03 | | |
| 26 | “Авылымның тырыш кешеләре”<br>Татарга хас булган тырышлык, сәүдә эшенә хирыслык, һөнәрчелек,. кече эшмәкәрлек турында өйрәнү.(Һәр авылның тырыш кешеләре, матур традицияләре була. Шулар үрнәгендә өйрәнү.)<br>Әңгәмә | 23.03 | | |
| 27 | Халык педагогикасына нигезләнеп, татар балалар фольклорын өйрәнү. Милли бәйрәмнәр, йолалар, милләтнең традицияләре турында белү.<br><br>Халык иҗаты әсәрләре<br><br>Җырлар, такмаклар, мәзәкләр, балалар сөйләшләре, сынамышлар һ.б.туплау. | 06.04 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Китапчык итеп әзерләү.<br>Эзләнү | | | |
| 28 | Көз фасылы белән бәйләнгән бәйрәм – йолалар.<br>Сөмбелә.<br>Авылда көзге эшләр тәмамлангач үткәрелә торган “Сөмбелә” бәйрәме тарихы.<br>Әңгәмә | 13.04 | | |
| 29 | Каз өмәсе .<br>Каз өмәсе тарихы турында өйрәнү.<br>Әңгәмә. | 20.04 | | |
| 30 | Милли бәйрәмнәр.<br>Нардуган.<br>Нардуган бәйрәме тарихын өйрәнү.<br>Әңгәмә. | 27.04 | | |
| 31 | Мили бәйрәмнәр.<br>Нәүрүз.<br>Нәүрүз бәйрәме тарихын өйрәнү.<br>Әңгәмә. | 04.05 | | |
| 32 | Милли бәйрәмнәр.<br>Сабантуй.<br>Сабантуй бәйрәме тарихын өйрәнү.<br>Әңгәмә | 11.05 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 33 | “Гүзәл җиребезне саклыйк!”<br>Туган төбәк, туган авыл турында белгәннәрне бер системага салу.Экологик белем һәм тәрбия буенча өйрәнелгәннәрне ныгыту.<br>КВН | 18.05 | | |
| 34 | Эшләнгән эшләргә йомгак Проект эше.<br>Эзләнү, күзәтү, җыйнал-ган материалларны өйрәнү, проект эше эшли белү.<br>Әңгәмә<br>Презентация<br>Уен<br>Проект эше | 25.05 | | |
| 35 | Проект<br>Җыйналган материаларны берләштерү, эшләнгән эшнең нәтиҗәле булуы, эшләгән эшеңнән тәм, матурлык, өмет, яшәү көче, энергия алырга өйрәнү. Дуслык, кешелеклелек, ярдәмчел булу, коллективта үзеңне ничек тоту,кыюлык,милләтпәр-вәлелек кебек сыйфатларны булдырырга өйрәнү.<br>Очрашу<br>Әңгәмә Проект эше | 25.05 | | |

Эшчәнлек барышында кулланыла торган дидактик һәм методик материаллар:

- Рәсемле биремнәр (мөстәкыйль эшләү өчен)
- Фотокарточкалы биремнәр ( яңа материал өйрәнү өчен)

- Сораулы биремнәр (группалап эшләү өчен)
- Ребус, кроссворд, табышмаклар;
- Хикәяләр;
- Әкиятләр;
- Уеннар;
- Экспонатлар;
- Презентация;
- Интернет материаллары;

**Кулланылган әдәбият:**

1.М.А.Вәлиуллин “Балачак илендә” “ Идел – Пресс”, 2009.
2. И.Х.Мияссарова “Табигать һәм балалар” Татар гуманитар институты, 2003.
3. Ә.Н.Хуҗиәхмәтов “ Тәрбия дәресләре” “Матбугат йорты”, 1998.
4. “Татар балалар фольклоры” “Раннур”. 1999.